Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе
«Мамадыш шәһәре 10 нчы «Миләшкәй» балалар бакчасы»

Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Детский сад № 10 «Милэшкэй» города Мамадыш»
Мамадышского муниципального района Республики Татарстан

# “Икмәк – ил байлыгы, сүз – тел байлыгы”

ижади - мәгълүмати    проект




Автор:  бакча мөдире Галимханова Гүзәлия Рәис кызы

2026 ел.

## Проектка аңлатма язуы

Туган телне саклап калу бер яктан караганда дәүләт җаваплылыгындагы сәяси мәсьәлә булып тоелса да, бу һәр кешенең дә - халкы, милләте, иртәгесе алдында шәхси бурычы булып тора. Туган телебезнең киләчәге соңгы вакытта беренче чиратта ата-аналарның, тәрбиячеләрнең шәхси җаваплылыгына, аларның ана теленә мөнәсәбәтенә бәйле.

Дөнья якты булсын дисәң, үз өеңдә ут кабыз”- диелә халкыбыз әйтемендә. Без дә шушы әйтемнән чыгып, татар халкының тамырдан яшәп килгән рухи камиллек, пакълык, сафлык, гаделлек кебек сыйфатларын балаларыбызда тәрбияләү максатыннан озак сроклы “Икмәк - ил байлыгы, сүз – тел байлыгы” дигән иҗади - мәълүмати проект эшләдек.

Һәр кеше тормышында "икмәк" төшенчәсе тумыштан керә. Һәм кеше аңында икмәк өстәл өстендә генә түгел, ә әхлакый кыйммәтләрнең үлчәгече, кешегә фидакарь, туктаусыз хезмәт китерүнең символы да булып тоела.

**Проектның актуальлеге:**

Соңгы вакытта безне балаларның икмәккә булган мөнәсәбәте ешрак борчый.
Балаларга түбәндәге сорауларны бирдек:
Икмәккә без һәрвакыт сакчыл карыйбызмы?
Икмәкне кем туклану өчен куллана?
Кешеләрнең өстәлендә һәрвакыт икмәк булганмы?
Икмәк уңышы һәм кибет киштәләренең төрлелеге нәрсәгә бәйле?
Икмәк безнең өстәлгә ничек әләгә?
Аны үз өстәлебезгә сатып алу турында кем кайгырта?
Бу сорауларга төркемнең 48% баласы җавап бирә алмады. Балаларның калган 52% ы җаваплар белән авырлаша, аларның тема буенча белемнәре бик ярлы. Хәзерге вакытта балаларда икмәкнең кыйммәте, икмәк үстерү процессы, икмәк җитештерүдә катнашучы кешеләрнең хезмәте турында белем җитәрлек дәрәҗәдә формалашмаган. Моңа ата-аналарның балаларда икмәккә карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү җитмәү дә ярдәм итә.
Бу тагын бер кат балаларның икмәк турындагы белемнәрен, аны алу ысулларын, игенчеләр, икмәк пешерүчеләр эшен киңәйтергә һәм тирәнәйтергә кирәклеген раслый. Балалар аның турында күбрәк белгән саен, аның кыйммәте арта бара. Без он, икмәк һәм игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләргә, шулай ук икмәккә сакчыл карарга өйрәтергә телибез.

**Максаты** - үз фикерен җиткерә белүче, үз ана телендә ирекле аралашырдай камил шәхес тәрбияләү.

**Бурычлары:**

1.Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
2.Инновацион технологияләр ярдәмендә балаларда иҗади активлык, коммуникатив күнекмәләр булдыру.
3. Балаларда патриотик хисләр тәрбияләү.
4.балаларда икмәк - күп кешеләрнең зур эш нәтиҗәсе дигән күзаллау формалаштыру.

5. Туган телгә өйрәтүдә гаилә белән хезмәттәшлек һәм иҗтимагый тирәлек (социум) белән арадашчанлык эшен камилләштерү.

**Проектның принциплары:**

- психологик комфорт;
- шәхси якын килү;
- яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу;
- дифференциалләштерү
- гаилә белән хезмәттәшлек;
- иҗтимагый тирәлек белән арадашчанлык;
- интегральләштерү.

**Тормышка ашыру вакыты**: озын сроклы (01.09.2025 – 31.05.2026)

**Проектта катнашучылар:** 1,5 – 7 яшьлек балалар, тәрбиячеләр коллективы, әти-әниләр.

**Проект төре:** иҗади - мәълүмати – практик

**Проектның ресурс тәэмин ителеше:**

<u>Норматив –хокукый ресурс:</u>

- педагогик киңәшмәдә раслау

<u>Кадрлар составы:</u>

13 педагог, 13 е дә – югары белемле,

7 се югары квалификацион категорияле, 6 – беренче квалификацион категорияле, 2 – СЗД.

Бакча хезмәткәрләре

<u>Фәнни-методик ресурслар</u>

Басма материаллар, методик һәм матур әдәбият

<u>Мәгълүмати ресурслар:</u>

Интернет-челтәрләр

Периодик басма ярдәмлекләр

5. <u>Материаль – техник ресурс</u>
   - интерактив панель,
   - 6 ноутбук ,
   - 4 экран,
   - 4 диапроектор,
   - күрсәтмә материаллар,
   - интерактив курчак-пособиеләр

**Материаль-техник тәэмин ителеш:**

**<u>Проектны тормышка ашыру формалары:</u>**

- шөгыльләр,

- экскурсияләр,
- әңгәмәләр,
- матур әдәбият уку,
- бәйрәмнәр,
- уеннар,
-театр эшчәнлеге,
- продуктив эшчәнлек,
- гаилә, иҗтимагый тирәлек белән хезмәттәшлек

**<u>Проектны тормышка ашыруның инновацион формалары</u>**

- проект эшчәнлеге,
- марафон,
- мастер-класслар,
- әдәбият геройлары парады,
- тематик рейдлар,
- музей педагогикасы,
- фестиваль,
- акцияләр,
- флеш-моб,
- ярминкә

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

1. Балалар икмәк барлыкка килү тарихы белән танышачак.
2. Балаларда икмәк әзерләү өчен ашлыкның нинди юл узуы турында күзаллау формалаша.
4. Балаларның һөнәрләр турында белемнәре артачак.
5. Балаларның сүзлек запасы яңа сүзләр белән баетылачак. Алар җөмләләрне дөрес төзергә, үз фикерләрен әйтергә өйрәнәчәкләр.
6. Балаларның иҗади сәләтләре үсәчәк.
7. Тәрбияләнүчеләрнең дөньяга карашы киңәйтелә.
8. Кеше өчен икмәкнең файдасы турында beләләр.
9. Проектка рецензия булачак.
10. Тәҗрибә уртаклашачакбыз.
11. Бакчаның иҗтимагый тирәлек белән бәйләнеше ныгыячак, рейтингы күтәреләчәк.

## Проектны тормышка ашыру этаплары

| № | Эш юнәлеше | Чаралар | Үтәлү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 - оештыру этабы | | | |
| 1 | Проектны өйрәнү һәм тормышка ашыру шартлары | Проектны тормышка ашыруда норматив-хокук документларын әзерләү | 01.09. 2025-30.09.2025 |
| | | Туган телдә белем бирү, сөйләм телен үстерү буенча предметлы- пространстволы тирәлекне булдыру, материаль – техник базаны ныгыту. | проект дәвамында |
| | | Педагогларның квалификациясен күтәрү | проект дәвамында |
| 2 | Мониторинг, критерийлар эшләү | Ана телендә белем һәм тәрбия бирү буенча бакча эшенә анализ. | сентябрь 2025 |
| 3 | Проектны тормышка ашыруда эш алгоритмын булдыру. | Проектның максатларын һәм бурычларын билгеләү | 01.09. 2025-30.09.2025 |
| | | Көтелгән нәтиҗәләргә ирешүдә каршылык тудыручы проблемаларны чишү | |
| | | Балаларга ана телендә белем бирүдә әти-әниләр белән эшләүнең эффектив алымнарын табу. | |
| | | Нәтиҗәләрне барлауда мониторинг системасын булдыру. | |
| 4 | Кадрлар белән тәэмин ителешне бәяләү | квалификация күтәрү курслары үтү | даими, план буенча |
| 2 - төп этап | | | |
| Балалар белән эш | | | |
| 1 | Татар телендә бәйрәмнәр һәм йолалар үткәрүне оештыру | “Бәби карау йоласы”<br>“Аулак өй”<br>“Кич утыру”<br>“Нәүрүз”<br>“Сабантуй”<br>“Питрау” | октябрь 2025-май 2026 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Сөмбелә” | |
| 2 | Рәсемнәр һәм кул эшләре күргәзмәсе (гаилә белән берлектә) | “Бөртекнең сәяхәт юлы”,<br>“Берегите хлеб” | октябрь-май, 2026 ел |
| 3 | Конкурслар оештыру | Әти-әниләр белән: «Хлеб — продукт чудесный, он любой — полезный»<br>Педагоглар белән:<br>“Иң яхшы үстерелешле уен” | март 2026,<br><br>апрель2026 |
| 4 | Традицион эш төрләре | Шөгыльләр үткәрү<br>Мультфильмнар карау<br>Сюжетлы – рольле уеннар уйнау<br>Хәрәкәтле, дидактик уеннар<br>Сәхнәләштерелгән тамашалар күрсәтү. | |
| 5 | Инновацион эш алымнары | Креатив биремнәр,<br>проект эшчәнлеге,<br>тикшеренү – эзләнү эшчәнлеге,<br>квест-уеннар,<br>синквейн - уен,<br>сәяхәтләр,<br>виртуаль экскурсияләр,<br>интервью,<br>акцияләр,<br>интерактив уеннар,<br>лепбуклар,<br>мнемотехнологияләр,<br>тематик рейдлар,<br>марафон,<br>парадлар,<br>флеш-моб | Проект дәвамында |
| | | **Педагоглар белән эш** | |
| 1 | Педагогик киңәшмәләр, семинар-практикум | “Сөйләм телен баетуда проект эшчәнлеген куллану”<br>“Проект эшчәнлегендә инженерлык фикерләү сәләтен үстерү” | ноябрь 2025<br><br>март 2026 |
| 2 | Кече проектлар яклау | “И түгәрәк ипи, ипекәй”,<br>“Икмәк булса, җыр да була”,<br>“Ашъяулыкта – ак кояш”,<br>“Икмәк кадере”,<br>“Авыл һөнәрләре”, | декабрь 2025 - май 2026 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Җыентык булдыру, рецензия алу | “Икмәк – зур байлык”,<br>“Хлеб – всему голова” | |
| 3 | Конкурс хәрәкәте | Район, региональ, Россия күләмендә узучы конкурсларда катнашу | проект дәвамында |
| 4 | Методик әсбаплар эшләү | <u>Проектлар җыентыгы:</u><br>“Икмәк - ил байлыгы,<br>тел – сүз байлыгы”<br><u>Методик эшкәртмә:</u><br>“Икмәк һәрнәрсәгә баш” - “Хлеб всему голова”<br><u>Дидактик уеннар:</u><br>«Тәме буенча әйт» (бодай, арыш ипие, батон, булочка и һ.б.) «Угадай на ощупь» (муляжи хлебных изделий)<br>"Охшаш сүзне тап",<br>“Икмәк нәрсәдән була?”<br>“Башак һәм бер телем икмәк”<br>«Кем күбрәк ипи ризыкларын атый»,<br>«Бөртекләрне арала»<br><u>Интерактив уеннар:</u><br>“Һөнәрләр иленә сәяхәт”<br>“Собери каравай”,<br>“Татар халык ашлары”,<br>“Кайсы артык”,<br>“Игенчегә ни кирәк” һ.б. | проект дәвамында |
| 5 | Чыгышлар, публикацияләр | Онлайн-семинарларда катнашу;<br>Региональ, республикакүләм узачак семинарларда чыгыш ясау;<br>Публикацияләр бирү | проект дәвамында |
| Әти-әниләр белән эш | | | |
| 1 | Ачык ишекләр көне, гомуми җыелыш үткәрү | шөгыльләр карау;<br>кичәләрдә булу;<br>күргәзмә, бәйгеләрдә катнашу | проект дәвамында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Информацион яктырту | Стендлар эшләү:<br>“Халыкара икмәк көне”,<br>“Икмәк - төрле халыклар арасында тынычлык һәм дуслык илчесе”<br>Күчмә папкалар, ширмалар | проект дәвамында |
| | | Официаль сайтка яңалыклар, информацион мәгълүмат кую.<br>Инстаграм, ВК, “Мамадыш-информ” сайтларында проект барышын яктыртып бару. | |
| | | “Икмәк – зур байлык” - бәйрәм чарасы | Апрель 2026 |
| 3 – йомгаклау этабы | | | |
| 1 | Проектны тормышка ашыруның эффектлылыгы | 1. Педагогик киңәшмә үткәрү:<br>1). Барлык проектта катнашучылар белән комплекслы рефлексия үткәрү.<br>2). Алга таба эш стратегиясен билгеләү.<br>3). Көтелгән нәтиҗәләргә ирешүдәге проблемаларны билгеләү.<br>4). Авырлыкларны ачыклау.<br>2. Проектны тәмамлау тантанасы.<br>Районкүләм чара үткәрү:<br>1).Фильм күрсәтү.<br>2). Проектны презентацияләү<br>3). “Икмәк табын түрендә” ярминкә үткәрү | Май 2026 |

Нәтиҗә.

Проектның максаты ирешелгән. Тема буенча белемнәрне диагностикалау түбәндәгеләрне күрсәтте: - Балалар уен һәм мавыктыргыч формада үзләре өчен яңа белемнәр алдылар, икмәкнең көндәлек азык продукты булуы турындагы күзаллауларны ачыкладылар һәм тирәнәйттеләр. - Икмәкнең кайдан алынуын һәм аны ничек җитештергәнен белдек. Өлкәннәрнең хезмәтенә хөрмәт, икмәккә сакчыл караш барлыкка килде. Тикшеренү эшчәнлеге күнекмәләре формалашты. Белем алу активлыгы, мөстәкыйльлек, иҗат үскән. Боларның барысы да табигатьне танып белүгә генә ярдәм итми, бәлки, үзендә кешелекнең абруен, яхшылыгын, бөтен тереклекне кайгыртырга ярдәм итә.

Балалар тикшеренү эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәләр ясый алдылар: Бодайны кырда гына түгел, тәрәзә төбендәге әрҗәләрдә дә үстереп була. Бөртекле культуралар, барлык үсемлекләр кебек үк, үсү өчен кирәк: уңдырышлы туфрак яктылык су җылы тәрбия (дөрес утырту, су сибү). Бодай - кыйммәтле һәм кирәкле азык-төлек, анда витаминнар күп. Аннан күп кенә ашамлыклар әзерләргә була (аннан он тарталар һәм бәлешләр пешерәләр, ботка пешерәләр, аш пешерәләр).

Ипи һәм икмәк-күмәч ризыкларының тышкы кыяфәте, зәвык сыйфатлары белән аерылып торган күп төрле төрләре бар. «Икмәк бар нәрсәгә дә баш» темасы буенча проект методын куллану балаларның белемнәрен системалаштыруга, ата-аналарны белем алу процессына җәлеп итүгә ярдәм итте.Белем бирү  процессын балалар өчен тагын да сыйфатлырак һәм кызыклырак итәргә этәрде.